БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13 октября 2022 ел № 145

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарында вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 5 өлеше, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1.1 пункты, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2004 елның 24 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде;

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының 2013 елның 19 декабрендәге 199 номерлы карары белән (2018 елның 1 ноябрендәге 150 номерлы, 2022 елның 18 декабрендәге 104 номерлы редакциядә) расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарында вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

«6) җирле үзидарә органнарының җитәкче вазыйфаларын Татарстан Республикасы тармак министрлыклары тарафыннан килештерү таләп ителә торган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә»;

1.2. Нигезләмәнең 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданины конкурс комиссиясенә тәкъдим итә:

1. Шәхси гариза;

2. 4х6 фотографияне беркетеп, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы боерыгы белән расланган форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета;

3. паспортның яки аны алыштыручы документның күчермәсе (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән тапшырыла);

4. кирәкле һөнәри белемне, эш стажын һәм квалификацияне раслый торган документлар:

- хезмәт кенәгәсе күчермәсе (эш (хезмәт) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш) яисә эш урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган, гражданның эш (хезмәт) эшчәнлеген раслый торган башка документлар. Эшләмәүче граждannар өчен - хезмәт кенәгәсенен күчермәсен беркетеп аның төп нөсхәсе;

- һөнәри белем турында, шулай ук граждан теләге буенча - нотариаль яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәтләре тарафыннан расланган өстәмә һөнәри белем турында, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турында документларның күчермәләре;

5. мәҗбүри пенсия иминияте иминият таныклыгының күчермәсе;

6. гражданның Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге 984н номерлы боерыгы белән расланган форма буенча муниципаль хезмәткә керүгә яки аны узуга комачаулаучы авыруның булмавы турында документ;

7. гамәлдәге законнарда каралган башка документлар.

1.3. Нигезләмәнең 17 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Конкурс уздыру өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарында вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру буенча комиссиянең бердәм составы төзелә һәм раслана»;

1.4. Нигезләмәнең 22 пунктындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләгәндә конкурс комиссиясе вакантлы вазыйфага карата тиешле квалификация таләпләреннән, вазыйфаи инструкция таләпләреннән, шулай ук муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән нигезләмәләрдән һәм Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, муниципаль хезмәт турындагы, коррупциягә каршы тору турындагы законнар нигезләреннән чыгып эш итә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе — Р.Р. Нотфуллин